ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
Әлдермеш авыл җирлегенең
Өбрә авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

6 декабрь 2021 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 6 декабрендә 16 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде. " 2022 елда балигъ булган һәр гражданнан 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә риза буласызмы? Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлегенең Өбрә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүчеләрдән алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга:

а) поселок эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;

б) 2021 елда үзара салым акчасын Өбрә торак пункты чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен төзелеш материаллары сатып алуга һәм янгын инвентаре саклау өчен ангар төзүгә, Өбрә торак пунктында поселок эчендәге юлларны карап тотуга һәм ремонтлауга юнәлдерү;

в) Тукай урамында ясалма тигезсезлекләрне төзекләндерү.

«ӘЙЕ» «ЮК»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия булган катнашучылар исемлегенә 111 (йөз унбер) катнашучы кертелгән, 59 ( илле тугыз) кеше тавыш бирүдә катнашкан, бу 53% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә билгеләнде:

халык җыенында 59 (илле тугыз) катнашучы «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлегенең Өбрә авылында халык җыены булып узды, Халык җыенының нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. 2022 елда үзара салым акчасын Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлегенең Өбрә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ

булган һәр кешедән 500 сум (биш йоз) күләмендә кертергә. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

а) поселок эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;

б) 2021 елда үзара салым акчасын Өбрә торак пункты чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен төзелеш материаллары сатып алуга һәм янгын инвентаре саклау өчен ангар төзүгә, Өбрә торак пунктында поселок эчендәге юлларны карап тотуга һәм ремонтлауга юнәлдерү;

в) Тукай урамында ясалма тигезсезлекләрне төзекләндерү.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче Н.А.Усманов